
# Мәчетләр каршындагы курсларда фикһ дәресләре укыту тәҗрибәсеннән

*Алсу Мөхәммәтшина,*
*”Казан нуры” мәчете каршындагы*
*“Шамил” мәдрәсәсе*

# Фикһның бүленеше



**Фикһ түбәндәге өлешләрдән тора:**

- **Әл-гыбадәт (гыйбадәт хөкемнәре) –** кешенең Раббысы Аллаһы Тәгалә белән бәйләнешен тәртипкә салучы хөкемнәр: намаз уку, ураза тоту, зәкят түләү, хаж кылу, нәзер, антлар һ. б.
- **Әл-мүгамәләт (мөгамәләт хөкемнәре) –** кешенең башка кешеләр белән булган бәйләнешен тәртипкә салучы хөкемнәр:
  1. **Әхвәл әш-шәхсия (шәхеснең халәтләре) –** туганнан алып вафатына кадәр кешенең халәтен аңлатучы хөкемнәр: никах, талак, нәселнең дәвамы, нәфәка бирү, имезү, мирас, васыять һ.б.;
  2. **Әл-мәлия (малга кагылышлы хөкемнәр) –** кешенең мал белән бәйле булган мөгамәлә итүен тәртипкә салучы хөкемнәр: сату-алу, бүләк, аренда, залог, ширкәтләр, мудараба, җаваплылыкны үз өстенә алу, вәкиллек итү һ. б.; милек белән бәйле мәсьәләләр: җир эшкәртү, ташландык җирләр, малны законсыз тартып алу, хәбәрсез югалганнар, вакыф һ. б.
  3. **Әл-гукубәт (җинаять хөкемнәре) –** җинаять кылу һәм җәза бирү белән бәйле хөкемнәр.
- **Әс-султания (дәүләт хөкемнәре) –** дәүләтне, хөкүмәтнең төзелеше, ватандашларның дәүләт белән бәйләнешен тәртипкә салучы шәригать хөкемнәре.
- **Әд-дәүлия (дәүләтара хөкемнәр) –** башка дәүләтләр белән бәйләнешләрне тәртипкә салучы шәригать хөкемнәре.

## Законодательство РФ

1. Конституция: права и свободы граждан, федеративное устройство, структура правительства, судебная власть, местное самоуправление; налоговый кодекс; бюджетный кодекс и др.
2. Гражданский кодекс.

Часть 1: опека, попечительство, ООО, ОАО, товарищество, фонды, деньги, валюта, ценные бумаги, сделки, представительство, доверенность, залог, поручительство, гарантия, договор, земельные участки и др.

Часть 2: купля-продажа, товар (качество, цена, оплата, поставка), недвижимость, дарение, рента, аренда, прокат, наем жилого помещения, подряд, кредит, банковский вклад, страхование, поручение и др.

Часть 3: наследственное право, завещание, международное частное право

Часть 4: права на результаты интеллектуальной деятельности, авторское право, патентное право, товарные знаки и др.

3. Трудовой кодекс: права и обязанности работника и работодателя, коллективные договоры, соглашения, трудовой договор, оплата заработной платы, отдых, охрана труда, дисциплина труда и др.
4. Семейный кодекс: заключение брака, развод, алименты, опека, усыновление и др.
5. Земельный кодекс.
6. Жилищный кодекс.
7. Кодекс об административных правонарушениях: административные наказания
8. Уголовный кодекс

Фикһның мөһимлеген аңлау өчен фикһ бүлекләре белән дөньяви дәүләт законодательствосы бүлекләрен чагыштырып карау файдалы. Шәкертләргә алдагы мәгълүматларга таянып, түбәндәге таблица белән эшләргә тәкъдим ителә. Сул якта фикһның бүлекләре язылган, ә уң якка әлеге бүлекләргә туры килә торган дөньяви дәүләт законодательствосы бүлекләрен язарга кирәк:

| **Фикһ бүлекләре (мөгаллим алдан әзерли)** | **Дөньяви законодательство бүлекләре (шәкертләр яза)** |
|---|---|
| **1. Гыйбадәт** | |
| **2. Мүгамәләт:** | |
| **2.1. Әш-шәхсия** | Гражданский кодекс, часть 1,3; семейный кодекс. |
| **2.2. Әл-мәлия** | Гражданский кодекс, часть 1,2; земельный кодекс, трудовой кодекс, жилищный кодекс. |
| **2.3. Әл-гукубәт** | Уголовный кодекс; кодекс об административных правонарушениях |
| **3. Әс-султания** | Конституция |
| **4. Әд-дәүлия** | Международное право |

# Фикһның үзенчәлекләре

**Фикһ һәм дөньяви законодательство бүлекләрен чагыштырганнан соң, шәкертләргә фикһның үзенчәлекләре турында нәтиҗәләр ясарга тәкъдим ителә. Нәтиҗәләр:**

- Фикһның чыганагы Коръән Кәрим һәм Сөннәт булып, Аллаһы Тәгалә ялгыз бер Үзе Кануннар чыгаручы булуы.
- Ислам шәригатенең аерым бер халык өчен генә түгел, ә бөтен кешелек дөньясы өчен иңдерелүе.
- Фикһның дөньяви һәм ахирәви булуы.
- Фикһның мәңге һәм үзгәрмәс булуы.
- Фикһның гакыйдә һәм әхлак белән тыгыз элемтәдә булуы.

# Гамәлләр

- Теманы аңлатканда гамәлләрнең төрләрен шкалага урнаштырып күрсәтү уңайлы: шкаланың ноль турысына – мүбах гамәлләр, нольдән өскә таба - яхшы гамәлләр, аска таба – начар гамәлләр хөкемнәре урнаштырыла:

# Гамәлләр


+
Фарыз
Вәҗиб
Сөннәт
Мүстәхәб
0
Мүбах
Мүстәкраһ
Мәкруһ
–
Харам

# Гыйбадәтләр (намаз, ураза, зәкят, хаж)

Гыйбадәтләр турындагы темаларны өч өлешкә бүлеп өйрәнергә була:

1. Әлеге гыйбадәт турында гомуми мәгълүмат, аның мөһимлеге, аны үтәгән кешенең өстенлекләре.
2. Әлеге гыйбадәтнең эчендә булган хөкемнәр: фарыз, вәҗиб, сөннәт, мәкруһ һ.б.
3. Әлеге гыйбадәтне кылу тәртибе (практик өлеш).

Һәр бүлектә үзенә хас методика файдаланыла.

Беренче бүлектә укучылар Коръән аятьләре, хәдисләрнең эчтәлеге турында фикерли, алардан мәгълүмат ала.

Мәсәлән, ураза темасын өйрәнгәндә, укытучы шәкертләрне берничә төркемгә бүлә, һәр төркемгә Коръән тәфсирләре тарата һәм “Әл-Бәкара” сүрәсенең 183, 185 нче аятьләрен табып укырга тәкдим итә.

# Ураза турында аятьләр

**“Әл-Бәкара” сүрәсе 183 аять:** “Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә рузә тоту фарыз ителгәне кеби сезгә дә, һәр елны бер ай рузә тоту фарыз ителде, шаять, рузәне калдырудан яки рузәга кимчелек китерүдән сакланырсыз!”

**185 аять:** “Рамазан ае бик шәриф ай, ул айда Аллаһудан кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидәятне ачык бәян кыйлучы Коръән иңдерелде. Сезләрдән  Рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә,  рузә тотсын! Рамазан аенда берәү чирле булса, яки сәфәрдә булса, башка вакытта каза кылырлар. Аллаһ сезгә җиңеллекне тели, вә сезгә авырлыкны теләми һәм Рамазан рузасын тутырып тотуыгызны һәм Аллаһ сезне туры юлга күндергәне өчен, Аллаһка тәкбирләр әйтеп, Аны зурлавыгызны тели, шаять, Аллаһка шөкер итәрсез!”

**Әлеге Коръән аятьләрен анализлаганда, түбәндәге нәтиҗәләр ясала:**

1. Исламга кадәр яшәгән кавемнәргә дә ураза тоту тиеш булган.
2. Уразаның хөкеме – фарыз.
3. Уразаны һәр елны бер ай тотарга кирәк.
4. Рузаны тотмый калырга ярамый, кимчелекләрсез тотарга тырышырга кирәк.
5. Уразаны Рамазан аенда тотарга кирәк.
6. Рамазан ае бик хөрмәтле ай, чөнки бу айда Коръән иңдерелә башлаган.
7. Коръән – кешеләргә туры юлны күрсәтүче Китап.
8. Авыру яки сәфәрдәге кешеләр ураза тотмаса да була, ләкин авыру терелгәч, сәфәрдәге кеше өенә кайткач, калдырган көннәре өчен ураза тотарга тиеш.
9. Рамазан рузасын тутыры, ягъни бер көн дә калдырмыйча тотарга кирәк
10. Аллаһ кешеләргә җиңеллек тели
11. Рамазан аенда безне туры юлга күндергәне өчен Аллаһы Тәгаләне зурларага, күп гыйбадәтләр кылырга кирәк.

(Башта шәкертләр фикерләре тыңланыла. Барлык нәтиҗәләр дә әйтелмәсә, укытучы өстәмә сораулар белән ярдәм итә).

# Рамазан ае турында хәдис

Бервакыт Рамазан ае килеп җитәрәк, Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм әйтте: “Бик мөбарәк булган Рамазан ае килеп җитте. Бу айда Аллаһы Тәгаләнең игътибары сезгә юнәлгән. Ул Үзенең Рәхмәтен иңдерә, гөнаһларны гафу итә, догаларны кабул кыла. Аллаһы Тәгалә сезнең хәерле гамәлләр эшләргә  омтылуыгызга карый һәм фәрештәләр каршында горурлана. Шулай булгач, Аллаһы Тәгаләгә яхшы гамәлләрегезне күрсәтегез. Чынлыкта, хәтта бу айда да Аллаһның Рәхмәтеннән коры калган кеше бәхетсез.

(Хәдиснең тексты язылган битләр төркемнәргә таратыла һәм югарыда китерелгән Коръән аятьләре кебек анализлана. Төркемнәргә төрле эчтәлектәге хәдисләр тарату тагын да отышлырак).

Икенче бүлектә гыйбадәтнең эчендә булган хөкемнәр (фарыз, вәҗиб, сөннәт, мәкруһ һ.б.) өйрәнелә. Әлеге теманы укытучы шәкертләргә, гадәттә, дәреслектәге  текстны файдаланып тәфсилләп аңлата, сорауларына җавап бирә.

Шәкертләрнең дәрестә активлыгын көчәйтү максатыннан, дәресне үткәрүнең икенче вариантын файдаланырга була: укучылар берничә төркемгә бүленә. Һәр төркемгә бер тема бирелә (мәсәлән, бер төркемгә  - намазның фарызлары, икенче төркемгә – намазның вәҗибләре һ.б.). Алар бер-берсе белән фикерләшеп, теманы өйрәнгәннән соң, аны башка төркемнәргә дә өйрәтәләр.


Теманы кабатлау өчен шәкертләр барлык хөкемнәр язылган карточкалар ясап килә. Әлеге ысул кыска вакыт эчендә шәкертләрнең теманы үзләштерү дәрәҗәсен белергә ярдәм итә. Укытучы теге яки бу гамәлнең хөкеме турында сорагач, шәкертләр җавап урынына тиешле карточканы күтәрә (алдагы слайдтагы фото):


Важиб
Фарыз
Сөннәт
Мөстәхәб
Важиб
Сөннәт
Фарыз

**Өченче бүлектә** шәкертләр гыйбадәтләрне практик яктан кылырга өйрәнә. Мәсәслән, намаз укырга өйрәну түбәндәге тәртиптә башкарыла:

- Намаз төрләре, намаз вакытлары, кыйбла, ният, азан, камәт турында мәгълүмат.
- Намаз уку тәртибе белән танышу (укытучы укып күрсәтә).
- Махсус төзелгән таблицадан  намаз уку тәртибе белән танышу (кара: кушымта №1).
- Намаз эчендә булган зикерләрне дөрес укырга өйрәну, ятлау.
- Укытучы белән бергә намаз уку.
- Схема ярдәмендә мөстәкыйль рәвештә намаз уку (схема - алдагы слайдта һәм кушымта №2 дә).


# Намаз уку тәртибе схемасы



Рамазан аенда ураза тотуның практик ягын өйрәнгәндә, шәкертләр белән Рамазан аен үткәрү план-проектын һәм аның үтәлүен тикшерү графигын төзү файдалы. Шәкертләр берничә төркемгә бүленә һәм киңәшләшеп план-проект төзи. Соңыннан һәр төркем үз планы белән таныштыра һәм гомуми план-проект төзелә (план-проектның үрнәген кушымта №3 тән кара).

Зәкят темасының практик ягын өйрәнгәндә, шәкертләр зәкят малының төрләре язылган таблицага үзләрендә булган малның суммасын язып (малы нисабка тулмаса, өйрәнү өчен якынча саннар файдаланып), зәкятнең хисабын чыгара (Кара: кушымта №4). Таблицага язганчы, иң элек малның зәкят түләнми торган өлеше саналып, гомуми суммадан чигерелә. Мәсәлән, арендага бирелә торган квартираның суммасына квартира өчен түләнә торган налог, квартплата кертелми һ.б. Барлык төр малларның бәясен бергә кушканнан соң 2,5 процентны исәпләп чыгарыла. Шул бирелергә тиешле зәкят була.

Хаж темасының практик ягын өйрәнгәндә, хаж кылу схемалары һәм хаж кылу урыннарының фотографияләре файдаланыла. Ахырдан,  залда символик рәвештә хаж кыла торга урыннар ясала һәм шәкертләр шул урыннарга тәртип буенча барып, тиешле гыйбадәтләрен кылып,  хаж гамәлен “үти”. Алдагы слайдларның беренчесендә зурлар өчен, икенчесендә – балалар өчен хаж кылу схемасы бирелгән.



МЕККА
КРАТКАЯ КАРТА ХАДЖА
Карта паломничества является краткой схемой, которая может использоваться для общего понимания процесса хаджа. Карта не может быть использована как руководство по хаджу, либо как карта ориентира на местности.
1 Ихрам
Первый день хаджа
Паломники входят в ихрам при прохождении миката.
2 Таваф
Первый день хаджа
Семикратный обход вокруг Каабы.
8 Четвёртый день хаджа
Паломники совершают прощальный таваф.
3 Мина
Первый день хаджа
Размещение паломников в лагере Мины.
4 Арафат
Второй день хаджа
Ритуальное стояние на горе Арафат.
5 Муздалифа
Второй день хаджа
Ночёвка в долине Муздалифа, Здесь собирают камешки для Жамарата.
6 Жамарат
Третий день хаджа
Обряд побивания камнями.
7 Ид аль-Адха
Третий день хаджа
Мусульмане отмечают праздник жертвоприношения.
Масджид аль-Харам
Мина
Муздалифа
Гора Арафат
Таваф
Паломники 7 раз обходят Каабу против часовой стрелки.
Са`й
Бег между холмами Сафа и Марва.
Зам Зам
Священный источник находится в 18 метрах от Каабы.

# Хаж кылу схемасына аңлатма

1. Хаҗилар Мәккәгә барып җиткәнче “микат” дип атала торган җирләрнең берсендә туктап, ихрамга керәләр, ягъни, мыекларын кыскарталар, тырнакларын кисәләр, тәннәрендәге артык төкләрен кыралар, госел коеналар, гадәттәге киемнәрен салып махсус ихрам киемнәре kияләр.
2. Мәккәдә Кәгъбәтуллаһ тирәли 7 тапкыр тәваф кылалар, “Мәкам Ибраһим” дигән җирдә ике рәкәгать намаз укыйлар, Зәм-зәм коесыннан су эчәләр, Сафа һәм Мәрва исемле ике кечкенә тау арасында йөреп, сәгыя кылалар.
3. Мина исемле бер авыл янындагы мәчет тирәсенә барып, анда бер кич куналар.
4. Гарәфәт тавына барып, башта өйлә намазын, аннан соң шул ук вакытта ук икенде намазын да укыйлар. Госел коенып, Гарәфәт тавына басып, Кыйблага каршы торып зикер әйтәләр, максатларын сорап дога кылалар
5. Кояш баегач, “Мөздәлифә” исемле җиргә барып, башта ахшам намазын, аның артыннан ук ястү намазын укыйлар. Төнне “Мөздәлифә”дә үткәреп, иртәнге намазны укыйлар.
6. Иртән яңадан Минага кайтып, андагы махсус урында җиде мәртәбә таш аталар.
7. Минада махсус урында корбан чалалар.
8. Мәккәгә кайтып, фарыз булган тәвафны кылып, ихрамнарын төгәллиләр.

# Хадж




لَبَّيْكَ اللَّهُمَّ لَبَّيْكَ،
لَبَّيْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ لَبَّيْكَ،
إِنَّ الْحَمْدَ وَ النِّعْمَةَ لَكَ
وَ الْمُلْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ


«Вот я перед тобой, о Аллах,
нет у Тебя сотоварища, вот я перед Тобой;
поистине, хвала Тебе, и милость принадлежит Тебе
и владычество, нет у Тебя сотоварища!»

**Основные этапы совершения хаджа:**

1. обойти 7 раз против часовой стрелки вокруг Каабы;
2. пробежать 7 раз между горами Сафа и Марва;
3. переночевать в Мине;
4. отправиться в долину Арафат и весь день молиться;
5. переночевать в Муздалифе;
6. вернуться в Мину, где бросить камушки в столбы и принести жертву животное;
7. вернуться в Мекку и ещё раз обойти 7 раз вокруг Каабы.

www.lezgikids.com












haj.ucoz.ru


haj.ucoz.ru





جبل قبيس
باب ابراهيم
مقام حنبلی
حجر اسود
حجر اسماعيل
مقام حنفی
زمزم
مقام ابراهيم
باب النبی
باب علی
باب عباس
باب النبی
باب السلام
مروه